**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2209**
**05.04.2024**

«Елның иң яхшы территориаль
иҗтимагый үзидарәсе» шәһәр
конкурсы үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең тотрыклы эше һәм үсеше өчен уңайлы шартлар формалаштыру максатында, Башкарма комитетның 2023 елның 31 октябрендәге 10494 номерлы Карары белән расланган «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы кысаларында, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) 2024 елның 10 июненнән 2024 елның 8 июленә кадәр үткәрергә.
2. Расларга:
1) Конкурс турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;
2) конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.
3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм аңа йомгак ясау чыгымнарын финанслауны шәһәр бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләр» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 500 000 (биш йөз мең) сум күләмендә тәэмин итәргә.
4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм Интернет челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 5 апрелендәге
2209 номерлы карарына
1 нче кушымта

Конкурс турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Конкурс турында нигезләмә «Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» шәһәр конкурсын (алга таба - конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурс 2024 елның 10 июненнән 2024 елның 8 июленә кадәр үткәрелә.

3. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитет шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлеге (алга таба – идарә) тора.

4. Конкурс территориаль иҗтимагый үзидарә (алга таба - ТИҮ) эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, халыкның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча үз инициативаларын гамәлгә ашыруда эшлекле һәм социаль активлыгын үстерүгә һәм стимуллаштыруга, йорт яны территорияләрен карап тоту, төзекләндерү һәм яшелләндерүдә халык инициативасын үстерүгә, халыкны торак фонд сакланышын тәэмин итү эшендә катнашуга җәлеп итүгә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү өчен уңайлырак шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

5. Конкурсның бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ТИҮ территориясен төзекләндерү буенча, халык ялының сыйфатын күтәрүгә ярдәм итү буенча, шәһәр территориясендә яшәүче халык белән эшләү буенча эшчәнлекне аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашыра торган ТИҮне ачыклау;

2) уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

6. Конкурста катнашучы булып, конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявкалар) биргән ТИҮ (алга таба – катнашучылар) тора.

7. Конкурста катнашу өчен катнашучылар Башкарма комитетның тиешле район хакимиятенә (алга таба - хакимият) заявка бирә, ә хакимият 2024 елның 10 июненнән 2024 елның 24 июненә кадәр түбәндәге документларны (алга таба - конкурс материалы) Башкарма комитет шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлегенә җибәрә:

1) гариза:

2) узган календарь ел өчен ТИҮ эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат (төрле формада бирелә: видеоматериаллар, фоторәсемнәр, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган материаллар җыелмасы һ.б.).

Заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң, барлык конкурс материаллары конкурс комиссиясенә тапшырыла.

8. Конкурста катнашуга заявканы кире кагу өчен нигез булып документларның тулы булмаган пакеты тапшырылу, бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы, шулай ук документларның заявка бирү өчен билгеләнгән датадан соң бирелүе тора.

9. Конкурсны оештыручылар, конкурста катнашучыларның ризалыгы буенча, конкурска тапшырылган материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә урнаштыру өчен файдалану хокукына ия.

10. Конкурс комиссиясе составы Башкарма комитет карары белән раслана. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм конкурс комиссиясе әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясенең сан ягыннан составы биш кешедән ким була алмый.

11. Конкурс комиссиясе әгъзалары түбәндәгеләргә вәкаләтле:

1) конкурс комиссиясе утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) конкурс комиссиясе утырышында катнашырга;

3) конкурска тапшырылган конкурс материалларын карап тикшерергә;

4) конкурста катнашуга заявканы кабул итү яки кире кагу турында карар кабул итәргә;

5) тәкъдим ителгән материаллар буенча баллар куярга;

6) конкурска йомгаклар ясарга һәм җиңүчеләрне билгеләргә.

12. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аңа йөкләнгән бурычлар үтәлешен тәэмин итә;

2) конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә.

13. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары конкурс комиссиясе әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) конкурс комиссиясе рәисе боерыкларын үти;

2) конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара.

14. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурс комиссиясен үткәрү урыны, вакыты турында хәбәр итә;

2) конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен алып бара;

3) конкурс комиссиясе рәисе һәм аның урынбасары боерыкларын үти;

4) конкурс комиссиясе бурычлары нигезендә аның эшен оештыра.

15. Конкурс комиссиясе утырышында әгъзаларның кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

16. Түбәндәге очракларда конкурс үтмәгән дип таныла:

1) конкурста катнашуга заявкалар булмау;

2) конкурста катнашу өчен бер заявка керү.

## 3 бүлек. Конкурсны бәяләү критерийлары

17. Конкурс комиссиясе тәкъдим ителгән заявкаларны карап тикшерә һәм әлеге конкурс турында нигезләмәгә кушымтада каралган бәяләү кәгазе буенча, конкурска тапшырылган мәгълүматка бәя бирә.

18. «Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» номинациясендә бәяләү критерийлары:

1) территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру:

- өмәләр оештыру;

- агач утырту;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген һәм казанышларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;

3) гражданнарның социаль яктан зәгыйфь категорияләренә ярдәм күрсәтү буенча ТИҮ эше (өлкән яшьтәге ялгыз кешеләр, инвалидлар, күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләр, шулай ук туендыручысын югалткан гаиләләр);

4) ТИҮ территориясендә мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары үткәрү;
5) ТИҮнең халык мөрәҗәгатьләре белән эшләве;
6) ТИҮнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлеге;
7) «Интернет» челтәрендә ТИҮ эшчәнлеген яктырту:
- социаль челтәрләрдәге битләр (500 һәм аннан күбрәк язылучылар);
- төрле мессенджерларда әңгәмәләр (әңгәмәдә 700 һәм аннан күбрәк кеше);
8) ташландык, хуҗасыз һәм тулы булмаган комплектлы транспорт чаралары хуҗаларын ачыклау буенча эшләр үткәрү;
9) ТИҮ территориясендә «Иң яхшы йорт, ишегалды (урам), подъезд, чәчәклек» исеменә конкурслар үткәрү;
10) ТИҮнең төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашуы.

19. Баллар суммасы конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан барлык критерийлар буенча билгеләнә, конкурсның йомгаклау билгесе һәр катнашучы буенча куела. Бәяләү йомгаклары буенча катнашучылар рейтингы төзелә.

20. Конкурс комиссиясе карары буенча, проектларны бәяләү өчен махсус белемле һәм квалификацияле экспертлар җәлеп ителергә мөмкин.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

21. Карар конкурсның һәр катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә һәм конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

22. Конкурсны үткәрү өчен гомуми фонд 500 000,00 (биш йөз мең) сум тәшкил итә.

23. Конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс җиңүчеләрен - ТИҮне бүләкләү өчен түбәндәге күләмдә грантлар бирү турында карар кабул ителә:
- 50 000,00 (илле мең) сум күләмендә гран-при бирү;
- беренче урын алган өч җиңүченең һәркайсына 40 000 (кырык мең) сум;
- икенче урын алган өч җиңүченең һәркайсына 35 000 (утыз биш мең) сум;
- өченче урын алган өч җиңүченең һәркайсына 30 000 (утыз мең) сум;
- дүртенче урын алган өч җиңүченең һәркайсына 25 000 (егерме биш мең) сум;
- бишенче урын алган өч җиңүченең һәркайсына 20 000 (егерме мең) сум.

24. Конкурска йомгак 2024 елның 4 июленнән 2024 елның 8 июленә кадәр ясала.

## 5 бүлек. Грант бирү

25. Конкурс комиссиясенең карары нигезендә, Башкарма комитет ТИҮ ассоциацияләре белән конкурс җиңүчеләренә грант бирү турында шартнамә төзи.

26. Конкурс җиңүчеләренә грант акчалары бирү турында шартнамә нигезендә, ТИҮ ассоциацияләре шәһәр конкурсында җиңүчеләр белән ТИҮ рәисен һәм активын бүләкләүгә грант акчалары бирү турында шартнамә төзи.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина

Конкурс турында
нигезләмәгә кушымта

## Бәяләү кәгазе

| № т/б | Күрсәткеч | Зурлыгы | Күрсәткечләр буенча аңлатмалар, мәгълүмат чыганагы | Күрсәткеч (баллар) зурлыгын бәяләү | Фактик баллар | Максималь мөмкин баллар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру - өмәләр оештыру - агач утырту | чаралар саны, үткәрү форматы, датасы | фотоматериаллар/ презентацияләр/ бастырып чыгарылган материаллар | 10 чарадан ким - 2 балл<br>10 чарадан артык - 5 балл | | 5 |
| 2. | Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген һәм казанышларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | бастырып чыгарылган материаллар саны (урнаштыру даталары һәм чыганаклары) | Фото һәм видеоматериаллар | бастырып чыгарылган материаллар һәм сюжетлар саны:<br>10 нан ким - 2 балл<br>10 нан артык - 5 балл | | 5 |
| 3. | ТИҮнең социаль яктан зәгыйфь гражданнар категориясенә (өлкән яшьтәге ялгыз кешеләр, инвалидлар, күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләр, шулай ук туендыручысын югалткан гаиләләр) ярдәм күрсәтү буенча эше | чаралар саны, үткәрү форматы, датасы | Фото һәм видеоматериаллар | Әйе - 10 балл<br>Юк - 0 балл | | 5 |
| 4. | ТИҮ территориясендә мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары үткәрү | чаралар саны, үткәрү форматы, датасы | Фото һәм видеоматериаллар | 1 дән 5 кә кадәр чара - 2 балл<br>6 һәм аннан күбрәк чара - 5 балл | | 5 |
| 5. | ТИҮнең халык мөрәҗәгатьләре белән эшләве | уңай хәл ителгән мөрәҗәгатьләр өлеше | уңай хәл ителгән мөрәҗәгатьләр/ мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны х 100% | Баллар гомуми мөрәҗәгатьләр санынннан уңай хәл ителгән процентларда үзгәреп тора<br>80% һәм аннан күбрәк - 5 балл,<br>80% тан ким - 2 балл<br>50% тан ким - 0 балл | | 5 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | ТИҮнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлеге | киңәшмә органнарның очрашулар саны һәм аларда карап тикшерелә торган мәсьәләләр | Фото һәм видеоматериаллар | Очрашулар саны 26 һәм аннан күбрәк - 5 балл 25 тән ким - 0 балл | | 5 |
| 7. | ТИҮ эшчәнлеген «Интернет» челтәрендә яктырту: - социаль челтәрләрдәге битләр (500 һәм аннан күбрәк язылучылар) төрле мессенджерларда әңгәмәләр (әңгәмәдә 700 һәм аннан күбрәк кеше) | социаль челтәрләрдә һәм мессенджерлар да актуаль мәсьәләләр буенча постлар урнаштыру | Сылтамалар, скриншотлар | 1 атнада урнаштырылган постлар саны 2 дән ким пост - 2 балл 3 тән артык пост - 5 балл | | 5 |
| 8. | Ташландык, хуҗасыз һәм тулы булмаган комплектлы транспорт чаралары хуҗаларын ачыклау буенча эшләр үткәрү | ТИҮ территориясендә күрсәтелгән транспорт чаралары булу | фотоматериаллар/ презентацияләр/ бастырып чыгарылган материаллар | 1 дән 4 кә кадәр - 2 балл 5 һәм аннан күбрәк - 5 балл | | 5 |
| 9. | ТИҮ территориясендә «Иң яхшы йорт, ишегалды (урам), подъезд, чәчәклек» исеменә конкурслар үткәрү | исеме, үткәрү датасы | фотоматериаллар/ презентацияләр/ бастырып чыгарылган материаллар | әйе - 10 балл юк - 0 балл | | 5 |
| 10. | ТИҮнең төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашуы | конкурслар саны, исеме | Дипломнар, грамоталар | Баллар катнашкан конкурс дәрәҗәсенә туры китереп билгеләнә: - шәһәр - 2 балл; - республика - 4 балл; - федераль - 5 балл | | 5 |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | 50 |
| Нәтиҗәлелек күрсәткече *(фактик баллар/максималь мөмкин баллар)* | | | | | % | |

Башкарма комитетның
2024 елның 5 апрелендәге
2209 номерлы карарына
2 нче кушымта

Конкурс комиссиясе
составы

| №<br>т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1 | Салахов<br>Фәрид Шавкат улы | конкурс комиссиясе рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2 | Зуев<br>Илья Сергеевич | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 3 | Лесникова<br>Марина Анатольевна | конкурс комиссиясе секретаре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлеге башлыгы |
| конкурс комиссиясе әгъзалары: | | |
| 4 | Альменеева<br>Эльвира Емельяновна | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары |
| 5 | Әхмәтҗанов<br>Ленар Илдар улы | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| 6 | Вилданов<br>Руслан Флер улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 7 | Елантьев<br>Андрей Владимирович | Шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |
| 8 | Фәттахов<br>Эдуард Рафаил улы | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |
| 9 | Харисов<br>Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина